**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 22 октябрь № 795

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы коллегиясе составын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2013 ел, 20 июнь, 421 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы коллегиясе составына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы коллегиясе составын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2013 ел, 20 июнь, 421 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 20 август, 608 нче карары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

коллегия составына Вәлиев Ленар Сәйдел улын – «Таткоммунпромкомплект» ААҖ генераль директоры урынбасарын – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисен кертергә (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\795.docx